# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $9^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $7^2$ пункт өстәргә:

“$7^2$) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуына, милләтара (халыкара) низагларны профилактикалауга юнәлтелгән гамәлләрне тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;”;

б) 23 пунктта “гражданнар оборонасы” сүзләренә кадәр “территориаль оборона һәм” сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $6^{2}$ пункт өстәргә:

“$6^{2}$) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятенә ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, азсанлы милләтләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларныц социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (халыкара) низагларны профилактикалауга юнәлтелгән гамәлләрне уйлап табу һәм тормышка ашыру;”;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торуны һәм карауны, карап тотуны гамәлгә ашыру очен шартлар тудыру, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыру;”;

в) $15^{1}$ пунктта “урнаштыруга рөхсәтләр бирү” сүзләрен “урнаштыру схемасын раслау, реклама конструкцияләре урнаштыруга һәм куллануга рөхсәтләр бирү” сүзләренә алмаштырырга, “яңа” сүзен төшереп калдырырга;

г) 21 пунктта “гражданнар оборонасы” сүзләренә кадәр “территориаль оборона һәм” сүзләрен өстәргә;

4) $16^{1}$ статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында “югары һөнәри белем бирүче муниципаль мәгариф учреждениеләрен” сүзләрен “югары белем муниципаль мәгариф оешмаларын” сүзләренә алмаштырырга;

5) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $7^{2}$ пункт өстәргә:

“$7^{2}$) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, шәһәр округы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятенә ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, азсанлы милләтләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (халыкара) низагларны профилактикалауга юнәлтелгән гамәлләрне уйлап табу һәм тормышка ашыру;”;

б) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган

балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торуны һәм карауны, карап тотуны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыру;";

в) $26^1$ пунктта "урнаштыруга рөхсәтләр бирү" сүзләрен "урнаштыру схемасын раслау, реклама конструкцияләре урнаштыруга һәм куллануга рөхсәтләр бирү" сүзләренә алмаштырырга, "яңа" сүзен төшереп калдырырга;

г) 28 пунктта "гражданнар оборонасы" сүзләренә кадәр "территориаль оборона һәм" сүзләрен өстәргә;

6) $17^1$ статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында "югары һөнәр белеменең муниципаль мәгариф учреждениеләрен" сүзләрен "югары белем муниципаль мәгариф оешмаларын" сүзләренә алмаштырырга;

7) 18 статьяның 1 өлешендәге $8^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$8^1$) җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларына, муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;";

8) 41 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Җирле бюджетларга, җирле бюджетларның чыгымнарын өлешләп финанслау өчен, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.";

9) 47 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен алар тарафыннан гамәлгә ашыруга җирле бюджетларга субвенцияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә.";

б) 3 өлештә:

беренче абзацта "Региональ компенсацияләр фондыннан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта "Региональ компенсацияләр фондыннан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга, "Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексында билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен "Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының "б" пунктчасыннан һәм 5 пунктының "б" пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының “б” пунктчасы һәм 5 пунктының “б” пунктчасы 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 9 декабре
№ 98-ТРЗ